# Рухи-әхлакый тәрбия буенча чара сценарие
# «Халкымның күңел дәрьясы»

Сценарийны музыка җитәкчесе Нуруллина Алсу Исламовна,
Татар теле тәрбиячесе Шәйдуллина Әдилә Вазиховна әзерләделәр.

**Аңлатма язуы:** Буыннан буынга күчә торган рухи тәҗрибә һәм йолалар вакытлар узу белән һич тә әһәмиятләрен югалтмыйлар, киресенчә, аларның кыйммәте арта гына. Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребез, йола, гореф-гадәтләребез яңадан торгызылып, яңартылып, заман төсмерләре биреп үткәрелә башлады. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән, милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә. Халык бәйрәмнәре, йолалары – кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Эш шунда ки, ул бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра. Яшь буын бәйрәмдә катнашу тәртибен кечкенәдән үк өйрәнеп үсә. Һәр кеше, табигый рәвештә, үз-үзен тоту гадәтләрен үзләштерә, милли тәрбия ала. Йола һәм гореф-гадәтләрнең күп кенә очракларда алыштыргысыз тәрбияви чара булуын да истән чыгармыйк. Тәкъдим ителгән чара нәкъ менә шушы максат һәм бурычларны тормышка ашырырга ярдәм итә.

**Максат:** Милли йолаларыбыз, бәйрәмнәребез балаларда милли хисләр формалаштыру, сөйләм телен, эстетик зәвыгын үстерү, халык авыз иҗатына кызыксыну уяту һәм милли горурлык тәрбияләү.

**Катнашалар:** Алып баручы, Әби, Мулла, Әни, Кыз, Кызлар, Малайлар.

**Чара барышы**

*(Өй күренеше. Тавыш ишетелә.)*

**Алып баручы:** Бала туды бүген җиргә,
Фәрештәләр аңа юл ачты.
Күкләр иле садә җаннан булган,

МАДОУ "Детский сад №261" Советского района г.Казани "Сәйлән"

Бер баласын җиргә озатты.

*(Матур көйгә әни, балалар чыгалар)*

**Әби:** Исәнме, килен. Исән-сау кайттыңмы?

**Килен:** Исәнме, әнкәй! Аллага шөкер кайтып җиттек.

**Әби:** Кайда әле безнең кызыбыз. *(Балага карап)* Сөбхан алла, бик матур бала бу.

**Килен:** Әйдәгез, кадерле кунаклар, бала йоклаган арада чәйләп алыйк әле. Ә син улым, бәбине карап тор яме. Уянса чакырырсың.

**Малай:** Ярар, әни.

**Алып баручы:** Кем дип исем кушарга, барысы да баш вата.

Олы дөнья каршысында исемсез бала ята.

Исем кирәк, исем кирәк, бирик без аңа исем.

Матурын сайлап куярбыз, исем кадерен белсен

**Бала:** __________, бәбигә исем сайладыгызмы? Кем дип кушасыз?

**Малай:** Әйдәгез бергәләп уйлык! Әллә иң элек бармак уенын уйныкмы?

*(Балалар түгәрәккә басалар)*

**Уен**

Бармак уены чыккан диләр.

Отылсам ярар иде.

Иң матур затлы исемне

Мин таба алсам иде.

*(Уртага бер баланы чыгара, бала уйлап тора да)*

**Бала:** Айрат! Шат күңелле, ачык дигән сүз!

**Малай:** Кит әле, безнең бәби бит кыз!

*(Тагын саный)* Бармак уены чыккан диләр.

Отылсам ярар иде.

Иң матур затлы исемне

Мин таба алсам иде.

**Бала:** Галимә! Укымышлы дигән сүз!

**Бала:** Авылыбызда Галимәләр болай да күп.

МАДОУ "Детский сад №261" "Сәйлән" Советского района г.Казани

**Бала:** Ярар алайса.

**Бала:** Мин таптым, мин таптым. Диләрә булсын!

**Бергә:** Булсын, булсын, бик күркәм,
Туры килсен үзенә.
Бай күңелле кызчык булсын,
Үссен безнең кечкенә!

**Малай:** Ник кычкырып сөйләшәсең, бәбәй уяна бит.

*(Бала елаган тавыш ишетелә.*
*Бишек янына барып бишек җырын җырлыйлар)*

**Бишек җыры**

Әлли - бәлли итәр бу, мәдрәсәгә китәр бу.
Тырышып сабак укыгач, галим булып җитәр бу. -2 *тапкыр.*

*(Әнисе бишек янына барып)*

**Малай:** Әни, әни бәбигә исем таптык!

**Әни:** Кем дип кушабыз, улым?

**Малай:** Диләрә дип кушабыз!

**Әни:** Бигрәк матур исем! Мәгънәсе дә бик дәрәҗәле: сөекле, иң яраткан, иң сөйгән дигәнне аңлата.

**Әби:** Аллага шөкер, исем дә уйлап таптык бит. Мулла килешенә әзерләник.

**Бергә:** Әйдәгез!

**Малай:** Әни, әни хәзрәт килә!

*Мулла керә*

**Мулла:** Әссәләмәгәләйкүм!

**Бергә:** Вәгаләйкүмәссәләм, мулла абзый!

**Әни:** Әйдә түрдән уз.

**Мулла:** Бик зур, рәхмәт. Әйдәгез әле өйгә дога укып алыйк. *(Дога укый)* Балага исем таптыгызмы?

**Бала:** Диләрә, Диләрә!

**Мулла:** Бәрәкаала, бигрәк матур, күркәм исем булган. Әйдәгез бәләкәч янына. *(фото 1)*

МАДОУ "Детский сад №261" Советского района г.Казани "Сәйлән"

*(Баланы бишектән алып, кереп китәләр)*

**Алып баручы:** Әзме, күпме вакыт узды....

*(Әби чыга, тәрәзәгә карап ала, өйләрне җыештырган була)*

**Әби:** Диләрә кызым килергә тиеш иде, күренми әле. Кайчан килер инде?

*(Кызлар килеп керәләр)*

**Диләрә:** Исәнме, әбием!

**Әби:** Исән-сау килеп җиттеңме, кызым?

**Кызлар:** Әйе, әби.

**Диләрә:** Әби, син ачуланма инде. Кызлар белән килгән идем.

**Әби:** Ярар, ярар, мин сезгә комачауламам, почмак якта гына утырырмын. Ә сез уйнагыз, көлегез. Безнең дә бар иде бит яшь чаклар… Без дә шулай аулак өйгә җыела торган идек. Егетләр килеп, күңел күтәреп китәләр иде. Ул уйнаган уеннар, җырлаган җырлар!.. Исәбе-хисабы юк иде.

*(Кызлар кул эше эшләп, җырлап утыралар)*

**Җыр “Шәл бәйләдем”**

Шәл бәйләдем, шәл бәйләдем – *2 тапкыр*
Шәлем түгәрәк түгел лә, шәлем түгәрәк түгел.
Әннә-гинер, әннә-гинер генәем лә.
Әннә-гинер, әннә-гинер генәем.

**Әби.** Бигрәк матур җырлыйсыз, кызлар! *(Як-ягына караныл)* Гармун тавышы түгелме соң бу? И, Аллам, егетләрегез килә бугай.

**Кыз:** Чынлап та кызлар, малайлар җырлап киләләр!

*Кызлар, урыннарыннан сикереп торып, төзәтенәләр.*

*(Әссәләмәгәләйкүм җырын җырлап  малайлар килеп керәләр)*

**Егетләр:** Әссәләмәгәләйкүм кызлар!

**Кызлар:** Исәнмсез егетләр!

Сезгә ни кирәк?

**Малай:** Кара кашлы кыз кирәк!

**Кыз:** Нәрсәгә ул кирәк?

МАДОУ "Детский сад №261" Советского района г.Казани "Сәйлән"

**Малай:** Әнигә килен кирәк!

**Кыз:** Ничек?

**Малай:** Менә шулай!

**Кыз:** Тупсадан акча түләмичә кертмибез. Акчагыз бармы?

**Егет:** Акча бездә бер кесә *(кесәләрен күрсәтәләр)*

**Әби:** *(Малайларны кертеп)* Кызлар, бу малайларның берниндидә акчалары юк. Шуңа күрә әйдәгез табышмаклар әйтик

**Кыз:** Соскы боры – бакылдык,
күп сөйләшә - такылдык. *(Үрдәк)*

**Кыз:** Башы тарак, койрыгы урак,
Кычкыртып быргысын, уята барысын. *(Әтәч)*

**Кыз:** Канат бар – очмый,
Аягы юк – йөри. *(Балык)*

**Әби:** Бигрәк акыллы икәнсез егетләр.

**Кыз:** Әйдәгез уйнап алабыз!

**Малай:** Әйдәгез Башмакчы уенын уйныйбыз!

**Бергә:** Әйдәгез!

**Уен "Башмакчы"**

Төрле һөнәр беләбез, матур итеп тегәбез.
Асыл төсле җепләр белән, башмак башын чигәбез.
Әй, башмакчы башмакчы, үзең оста такмакчы.
Син җырлама такмагың, бир кияргә башмагың – *2 тапкыр.*

**Әби:** Рәхмәт сезгә, оланнар. Яшь чаклар искә төште. Бигрәк күңелле уйнадыгыз. Бәй, онытып торам. Иртәгә бит сабантуй, әзерләнергә кирәк, таралышыйк балалар. Ә сабантуйдан соң кичке уен көтә! *(Кереп китәләр)* *(фото 2)*

**Сабантуй күренешләрен чагылдырган бию тезмәсе**

*(Күренештән соң кызлар, малайлар сәхнә артына кереп китәләр)*

*(фото 3)*

*(Кыз чыга)*

МАДОУ "Детский сад №261" Советского района г.Казани "Сәйлән"

**Диләрә:** Күмәк-бию, уен-көлке,

Була кичке уенда.

Кызлар, егетләр җыела,

Кичен бергә уйнарга!

*(Кызлар, егетләр чыгалар)*

**Кыз:** Егетләр килгәннәр, егетләр килгәннәр!

**Кыз:** Безнең монда җыелганны, әллә каян белгәннәр!

**Диләрә:** Әйдәгез уйнап алабыз!

**Кыз:** Әйдәгез "Без-без" уйныйбыз!

**Бергә:** Әйдәгез!

**Уен "Без-без"**

Без-без, без идек, без үнике кыз идек,

Базга төштек, май ашадык,

Келәткә кердек, бал каптык.

Кап та коп, авызыңны ачта йом.

**Малай:** Әмир, тешен күрсәтте!

**Кыз:** Нишләтәбез?

**Малай:** Бер аягында сикерсен!

*(Малай сикерә, калганнар кул чабып санныйлар)*

**Диләрә:** Әйдәгез тагын уйныйбыз!

**Диләрә:** Әйдәгез!

**Кыз:** Диләрә тешен күрсәтте!

**Кызлар:** Нишләтәбез?

**Малайлар:** Җырласын!

**Җыр**

**Диләрә:** Әйдәгез такмаклар әйтешик!

**Малай**. Әйдә ярышыйк, кем күбрәк белә икән?

**Малай:** Такмакка да мин оста,

Шакмакка да мин оста,

МАДОУ "Детский сад №261" Советского района г.Казани "Сәйлән"

Әти-әни эшкә кушса,

Мин авыру – мин хаста.

**Кыз:** Әнә килә автомобиль,

Төягәннәр алкалар.

Су алырга төшкән идем,

Узышалар бакалар.

**Малай:** Чуар тавык суга бара,

Аягында – чабата.

Шул вакытта оялмыйча

Ата каз йоклап ята.

**Кыз:** Агыйделдә бер бака,

Бер бата да, бер калка.

Шуны сиңа ошатып,

Көлеп эчләрем ката.

**Бергә:** Кызык булды!

**Малай:** Һай кызлары, кызлары, янып тора күзләре!

**Кыз:** Безнең бакча егетләре, берсеннән берсе матур.

Үзе матур, сүзе матур, туган илдә чын батыр!

**Малай:** Безенең бакча кызлары, берсеннән берсе чибәр.

Шул чибәрләр хөрмәтенә, тыпырдап биеп җибәр!

**Күмәк бию**

*(фото 4)*

МАДОУ "Детский сад №261" Советского района г.Казани "Сәйлән"

**Әдәбият:**


1. 261 балалар бакчасы тәрбиячеләренең әби-бабалары сөйләве буенча җыелган татар халык авыз иҗаты;
2. Татар халык уеннары / Төз. Р. Ягъфәров.- Казан : «Раннур», 2002.- 480 б.- («Юлдаш» газетасы китапханәсе).
3. Р. Ф. Ягъфәров, Йомгак таптым: Балалар фольклоры, - Казан: Мәгәриф нәшрияте, 2000;
4. Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен/төз. Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшрияте, 1984;
5. С. Саубанова, Бәйрәмнәр өчен, "Раннур" нәшрияте, 1999.


МАДОУ "Детский сад №261" Советского района г.Казани "СӘЙЛӘН"